# **Минем тормышымда укытучы**

Хәтерлим мин әле бүгенгедәй

Сентябрьнең бере җиткәнен...

Балачагым! Беренче укытучым минем! Мәктәбем минем! Күпме матур хатирәләр яши минем күңелемдә. Бик сагынып искә алам мин мәктәп елларын!

Беренче укытучым – Гөлфия апа. Аның мөлаем йөзе, чишмә чылтыравын хәтерләтүче яңгыравык тавышы, таләпчән карашы, тырышып-тырышып кул хәрәкәтләре белән дәрес аңлатулары, кигән матур киемнәре – барысы да күз алдымда.

Безне сөйде, безгә белем бирде

Рәхмәт аңа изге эше өчен!

Укытучы һөнәренә карата туган тирән хөрмәт, ихтирам оеткысын Гөлфия апа салды минем күңелемә.

Безнең өчен сез тир түккәнсез –

Сез иң гүзәл кеше икәнсез!

Менә шундый гүзәл кеше образы булып күңелдә мәңге калды минем беренче укытучым!

Шуңа да мәктәпне тәмамлагач, мин Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетына юл тоттым. Ел артыннан ел узган. Хәзер үзем балалар каршына басып дәрес бирәм. Инде 5 ел үтеп киткән. Әле дә булса хәтеремдә: беренче сыйныфта татар теле дәресе...

Күпме кызыксыну аларның йөзләрендә... Беренче дәресләремнең максаты – шушы хисне югалтмау. Моның өчен укытучы гына түгел, әни дә, әти дә, артист та, психолог та булу кирәк. Шатлык-көенечләре, уңышлары һәм уңышсызлыклары белән көн артыннан көн  үтте. Тырышлыгымның беренче нәтиҗәләре дә күренә башлады. Укучыларым дәрестә татарча сөйләмемне яратып тыңлыйлар, кызыксынып өйрәнәләр, сораулар бирәләр, йөзләрендә үз уңышларына сөенү чаткылары күренә, алар хәзер битараф түгел.  Инде минем

максатым – укучыларымда туган телебезгә хөрмәт, тирән мәхәббәт хисе тәрбияләү. И газиз туган телем минем, назлы телем, моңлы телем! Синең матурлыгыңны, моңыңны, камиллегеңне балаларга әйтеп бирә алсам иде.

И туган тел, и матур тел,

Әткәм-әнкәмнең теле.

Дөньяда күп нәрсә белдем

Син туган тел аркылы.

О язык родной, певучий!

О родительская речь!

Что еще на свете знал я,

что сумел я уберечь! *(перевод Равиля Бухараева)*

Укучылар дәрестә әйтелгән сүзләрне бик тиз истә калдыралар. Шул сүзләрне өйдә эти-әниләрегезгә дә өйрәтеп карагыз, дип тәкъдим итәм. Нәтиҗәдә, балаларга белгәннәрен башкаларга күрсәтү мөмкинлеге барлыкка килә. Димәк,тырышлыгым бушка китмәгән!

Заманалар үтү белән таләпләр дә, мөмкинлекләр дә арта. Бүгенге мәктәп алдында иҗади фикерләүче, аралаша белүче, талантлы шәхес үстерү бурычы куелган. Мөмкинлекләр бик күп, көн дә яңалык. Укытучыга ярдәмгә яңа педагогик технологияләр килә. Мин дә дәресләремне коммуникатив технологиягә, компьютер технологиясенә таянып үткәрәм. Төп максатым - балаларны туган телебездә аралашуга, аны көндәлек тормышта урынлы куллана белүгә өйрәтү. Мәсәлән, ситуатив күнегүләр куллану яхшы нәтиҗәләр бирә.

Мисал өчен:

- үзеңә дәфтәр сора,
- сора,
- дустыңнан бел,
- макта,

- комплимент әйт,

- уңай җавап бир,

- дустыңны кинога чакыр һ .б. Төрле сөйләм мәсьәләрен чишкәндә балалар телне өйрәнүнең әһәмиятен аңлыйлар. Укучыларым инде үз белемнәренә ышанып, бер-берсе белән татарча аралашалар. Дөрес, әле хаталар да җитәрлек, ләкин аларның бер-берсенең ялгышларын табып, төзәтеп ярдәм итүләре үзе дә минем өчен зур уңыш.

...Кайчандыр беренче сыйныфка укырга килеп, яңа тел өйрәнә башлыйлар. Хәзер инде зур егет-кызлар булдылар. Аларның туган телебезне яратып өйрәнүләре, инде матур итеп сөйләшүләре күңелләрне шатландыра. Татар телендә узган нинди генә чараларда катнашмыйлар алар! Мәктәптәме, шәһәркүләм дисеңме?!

Укучыларым татар теленнән үткәрелгән олимпиадаларда да актив катнашалар. 2016 нчы елны Лукоянова Татьяна беренче урынга лаек булды. Әйе, бу балаларыма алмашка башкалары үсеп килә. Башка укучылар белән дә тик тормыйбыз, шәһәр китапханәләре белән берлектә төрле бәйрәмнәр үткәрәбез, музейларга йөрибез, мәктәптә төрле чаралар үткәрәбез, “Зирәк тиен” бәйгесендә ел саен катнашабыз. Укучыларым тырыш, максатчан! Алар белән эшләү җиңел, рәхәт! Димәк, бергәләп куйган максатка ирешү дә җиңелрәк!

Халыкта тамчыдан күл җыела, дигән сүз бар. Без дә укучыларым белән тамчылап белем җыябыз.

Агач яфраклары төсле төрледән төрле укучыларымнан әдипләр, җир, су, күк кешеләрен аера алсам иде, талантлы шәхесләр, ә иң мөһиме – чын кешеләр үстерә, тәрбияли алсам иде. Нарасыйларым күңеленә нинди орлык чәчсәм – уңышы шундый булачак бит. Димәк, бүген мин киләчәк буын хәзерләүче остаз. Мин моны беркайчан да онытмам, онытмам, онытмам!!!